КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 сентябрь г.Казань № 1120

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс үткәрү турында» 2014 ел, 7 март, 146 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 июнь, 421 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 678 нче; 2016 ел, 18 февраль, 102 нче; 2017 ел, 5 июнь, 337 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1040 нчы; 2018 ел, 20 гыйнвар, 22 нче, 2018 ел, 29 декабрь, 1279 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс уздыру комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

әлеге карар белән расланган Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс уздыру турында нигезләмәдә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс (алга таба - Конкурс) ел саен хисап елында Казан шәһәрендә Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумын уздыру кысаларында энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән дәүләт хакимияте органнарын һәм бюджет өлкәсе учреждениеләрен, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен, оешмаларын бүләкләү максатларында уздырыла.»;

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Энергия саклау технологияләре үзәге» сүзләрен «Татарстан

Республикасының Энергия ресурслары нәтиҗәле технологияләре үзәге» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы» сүзләрен «Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның дүртенче абзацында «конкурс» сүзен «Конкурс» сүзенә алмаштырырга;

4.4 пунктта «Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы» сүзләрен «Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы» сүзләренә алмаштырырга;

4.6 пунктның җиденче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.7 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында «Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы» сүзләрен «Энергетика һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге буенча Татарстан халыкара форумы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

2 пунктның 3 графасында «дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктның 3 графасында «/предприятие» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада «Ф.И.А.и.» аббревиатурасыннан соң «(соңгысы - булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада «Ф.И.А.и.» аббревиатурасыннан соң «(соңгысы - булган очракта)» сүзләрен өстәргә.

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасында:

1.1 пунктның өченче абзацында «дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Бәяләү индикаторлары:

җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) биләп торган мәйданның 1 квадрат метрына җылылык энергиясен (җылылык энергиясен һәм табигый газны) тәэмин итүгә чагыштырма чыгым т.у.т./кв.метр;

җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) биләп торган мәйданның 1 кв.метрына электр энергиясен тәэмин итүгә чагыштырма чыгым, кВт·сәг/кв.метр;

җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) тәэмин итүгә суның 1 кешегә чагыштырма чыгымы, куб метр/кеше;

файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәпләү җайланмалары һәм җайга салу төеннәре белән җиһазландырылган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) өлеше, процент;

хисап чорында «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында мәгълүмат» дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә җирле

үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) төзелгән энергетика декларацияләре өлеше, процент;

муниципаль (дәүләт) заказчылары тарафыннан төзелгән энергия сервисы контрактлары булу, данә.»;

1.4 пунктның 1.4.6 пунктчасында «дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта:

1.5.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.1. Җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) тәэмин итүгә энергетика ресурсларын һәм суны чагыштырмача куллануны бәяләү индикаторлары буенча баллар түбәндәге формула буенча пропорциональ ысул белән исәпләнелә:

$$Б_{УД} = \frac{q_{min}}{q_{текущ}},$$

монда:

$q_{min}q_{min}q$minqqminmin - төркемдә муниципаль берәмлекләр (дәүләт учреждениеләре) арасында җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) тәэмин итүгә энергетика ресурсларын һәм суны чагыштырмача куллану күрсәткеченең минималь әһәмияте;

$q_{текущ}$ - җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) тәэмин итүгә энергетика ресурсларын һәм суны чагыштырма куллану күрсәткеченең агымдагы мәгънәсе.»;

1.5.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.2. Файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәпкә алу җайланмалары һәм җайга салу төеннәре белән җиһазландырылган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) өлешен бәяләү индикаторы буенча баллар түбәндәге формула буенча пропорциональ ысул белән исәпләнелә:

$$Б_{ПУ} = \frac{1}{6}\left(\frac{q_{текущ}}{q_{max}}\right),$$

$$Б_{ПУ} = \frac{1}{6}\left(\frac{q_{текущ}}{q_{max}}\right)$$

монда:

$q_{текущ}q$текущqqтекущтекущ$q_{текущ}$ - файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәләү җайланмалары һәм җайга салу төеннәре белән җиһазландырылган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) өлешенең тиешле күрсәткеченең агымдагы мәгънәсе;

$q_{max}$ - төркемдә муниципаль берәмлекләр (дәүләт учреждениеләре) арасында

файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәләү җайланмалары һәм җайга салу төеннәре белән җиһазландырылган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) өлешенең тиешле күрсәткеченең максималь мәгънәсе;

$\frac{1}{6}$ - энергетика ресурсларын һәм суны куллануны исәпкә алуның тиешле приборы белән тәэмин ителүен исәпкә ала торган сан коэффициенты (ресурсның теге яисә бу төрен урнаштыруга ихтыяҗ булмаса, коэффициент кими һәм тиешенчә була $\frac{1}{5}\frac{1}{4}$ $\frac{1}{3}\frac{1}{5}$$\mathit{1}51155\frac{1}{3}\mathit{1}31133$ , һ.б.).»;

1.5.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5.3. Хисап чорында «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында мәгълүмат» дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең (дәүләт хакимияте органнарының һәм дәүләт учреждениеләренең) төзелгән энергетика декларацияләре өлешен бәяләү индикаторы буенча баллар түбәндәге формула буенча пропорциональ ысул белән исәпләнелә:

$$Б_{ЭД} = \frac{q_{текущ}}{q_{max}},$$

монда:

$q_{текущ}$ - хисап чорында «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында мәгълүмат» дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең (дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт учреждениеләре) төзелгән энергетика декларацияләре өлеше күрсәткеченең агымдагы мәгънәсе;

$q_{max}$ - төркемдә муниципаль берәмлекләр (дәүләт учреждениеләре) арасында хисап чорында «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында мәгълүмат» дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең (дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт учреждениеләре) төзелгән энергетика декларацияләре өлеше күрсәткеченең агымдагы максималь мәгънәсе.»;

1.6 пунктның 1.6.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6.1. Йомгаклау баллы, суммар баллда бәяләүнең һәр күрсәткеченең авырлыгын билгели торган билгелелекнең билгеләнгән коэффициентларын исәпкә алып, һәр күрсәткеч буенча алынган барлык балларны кушып берләштерү юлы белән түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\sum Б = 0{,}4Б_{УД_{ОТ}} + 0{,}3Б_{УД_{ЭЭ}} + 0{,}1Б_{УД_{В}} + 0{,}1Б_{ЭСК} + 0{,}05Б_{ПУ} + 0{,}05Б_{ЭД} \sum Б = 0{,}4Б_{УДот} + 0{,}3Б_{УДээ} + 0{,}2Б_{УДв} + 0{,}05Б_{ПУ} + 0{,}05Б_{ЭД} \sum Б = 0{,}4\mathit{Б}УДотББУДотУДот + 0{,}3\mathit{Б}УДээББУДээУДээ + 0{,}2\mathit{Б}УДвББУДвУДв + \mathit{0{,}05Б}ПУ0{,}05Б0{,}05БПУПУ + 0{,}05\mathit{Б}ЭДББЭДЭД,$$

монда:

0,4; 0,3; 0,1; 0,1; 0,05; 0,05 – һәр бәяләү индикаторының күләмен суммар баллда билгеләүче әһәмиятлелек коэффициентлары;

$Бу_{Д_{ОТ}}$ $Бу_{Дот}$*Б*УДотББУДотУДот - җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) биләп торган мәйданның 1 квадрат метрына җылылык энергиясен (җылылык энергиясен һәм табигый газны) тәэмин итүгә чагыштырма чыгымны бәяләү индикаторы буенча исәпләнгән баллар;

$Бу_{Д_{ЭЭ}}$$Бу_{Дээ}$*Б*УДээББУДээУДээ - җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) биләп торган мәйданның 1 квадрат метрына электр энергиясен тәэмин итүгә чагыштырма чыгымны бәяләү индикаторы буенча исәпләнгән баллар;

$Бу_{Д_{В}}$$Бу_{Дв}$*Б*УДвББУДвУДв – җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль учреждениеләрне (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) су белән (кайнар һәм салкын) тәэмин итүгә 1 кешегә чагыштырма чыгымы;

$Б_{ЭСК}$ - муниципаль (дәүләт) заказчылары белән төзелгән энергосервис контрактлары булуын бәяләү индикаторы буенча исәпләнгән баллар;

$Б_{ПУ}$$Б_{ПУ}$*Б*ПУББПУПУ - файдаланыла торган энергетика ресурсларын һәм суны исәләү җайланмалары һәм җайга салу төеннәре белән җиһазландырылган җирле үзидарә органнары һәм муниципаль учреждениеләр (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) өлешен бәяләү индикаторы буенча исәпләнгән баллар;

$Б_{ЭД}$$Б_{ЭД}$*Б*ЭДББЭДЭД – хисап чорында «Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында мәгълүмат» дәүләт мәгълүмат системасының махсус модулендә җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең (республика башкарма хакимият органнары һәм дәүләт учреждениеләре) төзелгән энергетика декларацияләре өлешен бәяләү индикаторы буенча исәпләнгән баллар.»;

2.3 пунктның 2.3.1 пунктчасының икенче абзацында «файдалы» сүзен төшереп калдырырга;

4.1 пунктта «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.1 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктның өченче абзацында «/предприятиеләр» сүзен төшереп калдырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 6 июнь, 525 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 декабрь, 1402 нче, 2023 ел, 27 апрель, 531 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2022 – 2023 елларда электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектлары җиһазын

сатып алуга һәм электр автомобиль транспорты тиз заряд җыю өчен заряд җыю инфраструктурасы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) һәм индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 1.3 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2014 ел, 7 март, 146 нчы карары
белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 13 сентябрь, 1120 нче
карары редакциясендә)

Энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә иң яхшы казанышларга конкурс уздыру комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, комиссия рәисе |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Әхмәров Марат Равил улы | «Татарстан Республикасының Энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану технологияләре үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директоры |
| Гыйләҗиев Роберт Фәйзи улы | «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Гобәйдуллин Әгъзам Самат улы | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча) |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Коробченко Олег Владимирович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Миңнебаев Марат Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Хәйруллин Айрат Ринат улы | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры. |

___